**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 530

КАРАР
«15» 09 2022 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 465 номерлы карары белән расланган аукционнар үткәрмичә милеккә җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Административ регламентны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 465 номерлы карары белән расланган торглар үткәрмичә милеккә җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Регламентның 2.6.1 пунктындагы 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) инвалидлык билгеләү фактын раслый торган белешмәләр - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды;».

1.2. 2.8.2 пунктындагы 13 пунктчасында "бакчачылык" сүзен "гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару" сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Карарның 1.1 пункты законлы көченә керә - 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин